**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**НИЖНЕКАМЕНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Центральная , д.51, с.Нижняя Каменка,
423114

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КӘМИНКӘ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Үзәк урамы, 51 йорты, Түбән Кәминкә авылы,
423114

тел./факс(84396) 2-35-21 email: Nkam.Cmn2@tatar.ru

24 сентябрь 2018 ел №102

**КАРАР**
**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советы**

Түбән Кәминкә авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

12.06.2002 елның № 67 ФЗ "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" гы 15 статьясы нигезендә, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ Федераль законның "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары" турында 22,56 статьялары, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ "Җирле референдумтурында" Татарстан Республикасы законы , Түбән Кәминкә авыл җирлеге Уставы белән, Түбән Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 24 сентябрендәге Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советы "Референдум үткәрү инициативасы турында " гы 10 номерлы карары нигезендә **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга: "2019 елда үзара салым кертүгә 550 сум күләмендә Түбән Кәминкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булмаган, көндезге уку формасы

буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, калган гражданнардан алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга килешәсезме?"

- Түбән Кәминкә һәм Кара Чишмә торак пунктларында юлларны төзекләндерү, карап торуга хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабуга, юл-урам челтәренең юл кырыйларын норматив хәлгә китерүгә, юлларны грейдерлауга, кышын урамнарны кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары , запас частьләр сатып алуга , Түбән Кәминкә һәм Кара Чишмә торак пунктларында кирәкле материаллар сатып алуга) ;

- су белән тәэмин итү һәм суэтем башняларын ремонтлау,артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, коймаларны ремонтлау һәм буяу, суэтем башняларын буяу, павильон урнаштыру, каты өслекле юллар урнаштыру, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, Түбән Кәминкә һәм Кара Чишмә торак пунктларында проект-смета документлары өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.;

- Түбән Кәминкә һәм Кара Чишмә авылларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, янгын вакытында хәбәр итү системасын урнаштыру ,сулыкларның һәм янгын гидрантларының күрсәткечләрен урнаштыру ,ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәтләр өчен түләү.

"ӘЙЕ ЮК"

3. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» («Наш Черемшан») район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кәминкә авыл җирлеге советы рәисе,
җирле үзидарә башлыгы Р.Р. Халиков